**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«07» август 2024 ел** **№ 49/4**

Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елның 1 январе торышына аерым салым түләүчеләргә караган, түбәндәге нигезләр буенча түләп бетерү һәм (яки) түләтү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның, варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылган көннән алып бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта, бурычы булу;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамлангач, физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу;

3) физик затларның – 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, шулай ук 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның бурычы булу.

2. Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге карарның 1 пункты 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) физик затның вафат булуына бәйле рәвештә салым органнарында исәптән төшерелүе турында мәгълүматлар;

в) мираска хокук турында таныклык бирү хакында мәгълүматлар булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда: 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында салым органы белешмәсе;

3) әлеге карарның 1 пункты 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) махсус хәрби операциядә катнашучы статусын раслый торган документ.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Җирле салымнар буенча недоимкаларны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2020 елның 12 октябрендәге 2/5 номерлы;

- «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 14 июлендәге 35/1 номерлы;

- «Җирле салымнар буенча недоимкаларны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 12 октябрендәге 2/5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 5 мартындагы 44 номерлы карарлары.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе Г.Т. Хөсәинова